| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.10.2019 ел Баулы шәһәре №286

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 11 мартындагы 58 номерлы карары белән расланган «2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасына һәм өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 ст., 2нче бүлеге, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 11 мартындагы 58 номерлы карары белән расланган «2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

Программаның I «Муниципаль программа паспорты» бүлегендә «Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлында 2нче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Программаны гамәлгә ашыру өчен финанс чараларына гомуми ихтыяҗ 7 млн. 196 мең сум тәшкил итә (җирле бюджет, республика бюджеты акчалары). Искәрмә: Программаны финанслау күләме фараз булып тора һәм тиешле дәрәҗәдәге бюджетлар формалаштыруны исәпкә алып, тиешле елга һәм план чорына ел саен

төзәтмәләр кертергә тиеш»;

Программага 2нче «2019-2023 елларга Баулы муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасының төп чаралары исемлеге» кушымтасында «КУЭ субъектларына финанс ярдәме чараларын гамәлгә ашыру» 3 пункты 1 пунктчасына «җирле бюджет 7 млн.196 мең сум» сүзләрен һәм саннарын өстәргә.

2. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «2019 елның 11 мартындагы 58 номерлы карары белән расланган «Баулы муниципаль районында 2019-2023 елларга кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»гы 2019 елның 9 августындагы 229 номерлы карары гамәлдә түгел дип санарга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров